# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
Антоновка авыл җирлегенең Гусиха торак пунктында
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының

2024 елның 01 ноябрендәге 4 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлегенең Гусиха торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлегенең Гусиха торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- Гусиха торак пунктында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру килешү буенча эшләр өчен түләү);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; (Гусиха торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга мемориаль плитә кую (төзелеш материалы сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Гусиха торак пункты территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү (территорияне чабу, карны чистарту)).

3. Әлеге карарны Антоновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга ( http:// spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Антоновка авыл җирлеге башлыгы
Спас муниципаль районының В. С. Фролов

СОВЕТ
АНТОНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ